**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Березовка авыл җирлеге составына керүче Подлесный поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2022 нче елның 26 ноябре** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Подлесный торак пунктында гражданнарның җыены

Карар итте:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Подлесный поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.
2. Алынган акчаларны Гариф Закиров исемендәге урамга асфальт җәюгә юнәлдерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Березовка авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Ф.Сәлманов**